РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 02 2024 ел №82

2024 елның I кварталына
Ютазы муниципаль районы буенча
1 квадрат метр торак мәйданының
уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге №31-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен гражданнарны исәпкә кую һәм мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарга торак биналарда, муниципаль торак фондының торак урыннары социаль наем шартнамәләре буенча торак бирү максатларында исәпкә алу тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Ютазы муниципаль районында «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан 1 квадрат метр торак бинаның уртача бәясен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләре буенча, 2024 елның I кварталына Ютазы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын – 40 571 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә

органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
8(85593)2-42-05